ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11 10 2019 г. № 616

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Алкогольле продукция әйләнешен җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларын тормышка ашыру чаралары турында» 2013 елның 25 июнендәге 938 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Балалар, мәгариф, медицина оешмаларыннан һәм спорт объектларыннан, күпләп һәм ваклап сату базарларыннан, вокзаллардан, аэропортлардан һәм гражданнарның башка күпләп җыелу урыннарыннан һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары билгеләгән югары куркыныч чыганакларының урнашу урыннарыннан, хәрби билгеләнештәге объектлардан тирә-юнь территорияләре чикләренә кадәр ераклыкны исәпләү тәртибенә төгәллек кертү максатларында:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Алкогольле продукция әйләнешен җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларын тормышка ашыру чаралары турында» 2013 елның 25 июнендәге 938 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтаның искәрмәсен түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга:

«Исәп-хисап җәяүлеләрнең төзекләндерелгән җәяүлеләр юллары (тротуарлар) буенча йөрү юлы буенча башкарыла».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.И.Беляевка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов